Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«23» ноябрь 2022 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан кала балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту, грейдер белән тигезләү һәм киләчәктә яшеллек утырту өчен тыгыз нигез салу

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, вак таш сатып алу, хезмәт күрсәтүләр сатып алу,

- Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге өчен МТЗ - 82.1 тракторы һәм тагылмалы җиһазлар сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов